**СОВЕТ БОЛЬШЕКАБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Кәньяк урамы,1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2023 елның 12 декабре** **91 номер**

**КАРАР**

**«Җир салымы турында» 2021 елның 25 октябрендәге 39 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 25 октябрендәге 39 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 **2 пунктның 2.1 пунктчасының «в» абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм инвалидларын, шулай ук сугыш хәрәкәтләре ветераннарын һәм инвалидларын;»

2. Әлеге карарның нигезләмәләренең гамәлдә булуы, 2023 елдан башлап салым чорлары өчен җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Олы Кабан авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Олы Кабан**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **И.Г. Шәрәфиев**